# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ТЕЛӘЧЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ОЛЫ МӘТӘСКӘ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

## КАРАР
**алтынчы утырыш бишенче чакырылыш**

**4 май 2026 ел** **№ 18** **Олы Мәтәскә ав.**

**Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Олы Мәтәскә авыл җирлеге территориясендә махсус мәгълүмат стендларының урнаштыру урыннарын раслау турында**

«Гаммәви хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 53 статьясы, «Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Олы Мәтәскә авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Олы Мәтәскә авыл җирлеге Советы карар итте:

1. Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районының Олы Мәтәскә авыл җирлеге территориясендә махсус мәгълүмат стендларын урнаштыруның түбәндәге урыннарын расларга:

1) Татарстан Республикасы, Теләче муниципаль районы, Олы Мәтәскә авылы, Фатыйх Хөсни ур., 56А йорт (Теләче муниципаль районының «Олы Мәтәскә авыл мәдәният йорты» бинасы);

2) Татарстан Республикасы, Теләче муниципаль районы, Югары Мәтәскә авылы, Центральная ур., 17А йорт (Югары Мәтәскә авыл клубы бинасы );

3) Татарстан Республикасы, Теләче муниципаль районы, Ямбулат авылы,М. Ногманов ур., 18 (Ямбулат авыл клубы бинасы );

4) Татарстан Республикасы, Теләче муниципаль районы, Лесной поселогы, Татарстан ур., 8 йорт (Лесной авыл клубы бинасы);

5) Татарстан Республикасы, Теләче муниципаль районы, Тәмте Мәтәскә ав., Подгорная ур., 5 йорт (Тәмте Мәтәскә авыл кибете бинасы );

2. Әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән махсус мәгълүмат стендлары үзләрендә урнаштырыла торган мәгълүмат белән чикләнмәгән затлар даирәсе тарафыннан тоткарлыксыз танышу мөмкинлеген, шулай ук мондый мәгълүматны тышкы йогынтылардан яклауны тәэмин итәргә тиеш.

3. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга (https://pravo.tatarstan.ru/).

4. Әлеге карар рәсми игълан ителгән көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы
Олы Мәтәскә авыл җирлеге башлыгы Ш. В. Кәримуллин